ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

_25.10.2022_ Мөслим авылы №_606_

**2023 елга, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бәя нормативларын раслау турында**

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- 2023 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

- Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Мөслим муниципаль районы финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларында йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары нигезендә финанслау.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенең 2022 елның «25»
октябрендәге 606 номерлы
карары белән расланды

2023 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка (бер елга сумнарда) | автотранспорт чарасының бер километр узган юлына ставка (бер елга сумнарда) |
| ПАЗ | 613675 | 21,02 |
| ГАЗ «Газель» | 593227 | 13,56 |
| УАЗ | 592774 | 11,87 |
| FIAT | 596122 | 9,98 |
| Peugeot Boxer | 601272 | 9,61 |
| Ford Transit | 601529 | 13,74 |

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2022 елның 25 октябрендәге 606
номерлы карары белән расланды

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган автотранспорт чарасының хисап елында фактта узган юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m моделендәге автотранспорт чараларының фактта узган юлы (километр);

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер километрга (сумнарда);

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумнарда;

$M_m$ - m моделендәге автотранспорт чаралары саны (берәмлекләрдә);

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләренең саны.